ГЛАВА ПЕЧИЩИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Декабристов, д.35 а, с. Печищи,
422592

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ПЕЧИЩИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

17.11.2025 Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48. № 2-19

с. Печищи

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының
Печищи авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Печищи авылы җирлегендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын 2025 елның 30 ноябренә билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: “2026 елда Югары Ослан муниципаль районының Печищи авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (балалар мәйданчыгы җиһазларын сатып алу).

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Печищи авылы, Киров урамы, 62 йорт адресы буенча Печищи авыл клубы бинасында 11.00 сәгатьтә гражданнар җыенын үткәрергә.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Печищи авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге башлыгы В.Н. Журкин